ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр керту хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына керту буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр керту хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр керту хакында» федераль закон проектын бәяләмә алу өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

3. «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр керту хакында» федераль закон проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәте бәяләмәсен алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Күрсәтелгән федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкилләр итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Тыгин Александр Васильевичны билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына йөкләргә.

6. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

а) «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр керту хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына керту буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» 2020 елның 11 июнендәге 457-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2020, № 5 – 6);

б) «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр керту хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына керту буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» 2020 елның 11 июнендәге 457-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр керту хакында» 2020 елның 20 августындагы 556-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2020, № 7 – 8).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 23 декабре
№ 776-VI ДС